**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"24" ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә: 1) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Чишмәле Сап авылында кое ремонтына төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

2) күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Чишмәле Сап авылында зиярат коймаларын ремонтлау өчен төзү материаллары алу;

3) физкультура һәм массакүләм спортны үстерү:

- Чишмәле Сап авылында спорт мәйданчыгынын коймасын тотуга төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.